# Ашыктырма мәхәббәтне

1.Язгы ташу кебек

Килеп керер сөю,

Йөрәгеңне яулар,

Булмас аны тыю.

Кушымта:

Ашыктырма мәхәббәтне,

Синеке - сиңа булыр.

Чәчәклврдәй ташлар ярып,

Яныңа ул ашкыныр.

2.Әйбәт кеше очрый,

Синеке түгел шул.

Дөп-дөп типми йөрәк,

Ятмый гына күңел.

3.Давыл кебек килеп,

Үзгәртер тормышны.

Бәхет гөленә күмеп,

Ачыр йөрәгеңне.

*Сүзләр авторы: Резеда Шамсуллина*

*Башкара: Раиля Галимзянова*

*Җырга сылтама: https://vk.com/wall5684746_4738*